**СОВЕТ ЕКАТЕРИНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423196, РТ Новошешминский район с. Сл.Екатерининская, ул. Привражная д. 9.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЕКАТЕРИНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423196, РТ Яңа Чишмә районы ,Екатерина авылы, Привражная урамы, 9

Тел.:(8-4348)3-67-36,факс:(8-4348)3-67-36.Ekat.Nsm@tatar.ru.

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Екатериновка Бистәсе авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

“ 24 “ сентябрь 2018 нче ел № 58-98

## “ЯҢА ЧИШМӘ РАЙОНЫ ЕКАТЕРИНОВКА БИСТӘСЕАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БИЛӘМӘЛӘРЕНДӘ ҮЗАРА САЛЫМ ҖЫЮ ҺӘМ КУЛЛАНУ БУЕНЧА РЕФЕРЕНДУМ КӨНЕН БИЛГЕЛӘРГӘ”

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлауга хокукы һәм референдумда катнашуга хокукы турында”гы Федераль законның, 12 нче июнь 2002 нче ел “67-ФЗ, 15 нче матдәсе нигезендә, шулай ук “Россия Федерациясендә үзҗитәкчелекне оештыру турында” Федераль Законның, 6 нчы октябрь 2003 нче ел № 131-ФЗ, 22 нче, 56 нчы матдәсе нигезендә, “Җирле референдум турындагы” Татарстан Республикасы законы 24 нче март 2004 нче ел, № 23-ТРЗ, 17 нче, 18 нче матдәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы, “ Екатериновка Бистәсе авыл җирлеге” Устанының 11 нче матдәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Екатериновка Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 нче елнын14 сентябере № 24 номерлы”Референдум үткәрүгү башлангыч бирү” турындагы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Екатериновка Бистәсе авыл җирлеге Советының 2018 нче елнын 14 сентябере №57-97 номерлы ”Референдум үткәрүгә башлангыч бирү” турындагы карары нигезендә, Татарстан Респубикасы Яңа Чишмшә районы Екатериновка Бистәсе авыл җирлеге Советы

**КАРАР** бирә:

- Екатериновка Бистәсе авыл җирлеге биләмәсендә, үзара салым җыю һәм куллану буенча, 2018 нче елның 18 нче нояберенә референдум көнен билгеләргә.
- Референдумда каралачак сорауларны барларга:

“Сез , Екатериовка Бистәсе авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән, 2019 нчы елга, 400 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме. Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар,,

сугыш ветераннарының тол хатыннары,1 группа инвалидлар,Рәсәй армиясе сафларында хезмәт итүчеләр азат ителә.

-Юлларны ремонтлау һәм карап тору, шул исәптән юлларны кардан чистарту, урамнарны төзекләндерү,ягулык- майлау материаллары сатып алу,Екатериновка бистәсе авылы һәм Яңа Иванаево авылында чыгым материаллары һәм хезмәт хакы буенча килешүләргә;
-Екатериновка бистәсе авылының Советлар урамында һәм Яңа Иванаево авылының Болын урамында юлларны түшәүгә;
-Екатериновка бистәсе авылындагы чишмәне төзекләндерүгә(җәяүлеләр басмасына тотынгычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Екатериновка бистәсе һәм Яңа Иванаево авылында агымдагы обьектларны һәм су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерүгә,проект документларын төзү өчен түләүгә ;
- Яңа Иванаево авылында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәл өчен мемориаль такта әзерләүгә һәм урнаштыруга.

ӘЙЕ ЮК".

3.Карарны "Яңа Чишмә" район газетасында бастырырга.

4.Карар "Яңа Чишмә" район газетасы битләрендә басырылган көннән үз көченә керә.

5.Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә йөклим.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Екатериновка Бистәсе авыл
җирлеге башлыгы А.А. Харьков